**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«8» апрель 2022** **№ 65**

Мәҗбүри эшләр төрләрен һәм мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәза үтәлә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында

Мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәза билгеләнгән затларны төзәтү, аларда нормаларга, җәмгыять кагыйдәләренә, иҗтимагый файдалы хезмәткә карата хөрмәт уяту максатларында, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.13 һәм 32.13 статьялары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Билгеләргә:

А) административ хокук бозган физик затлар тарафыннан башкарыла торган Теләче муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр төрләре, 1 номерлы кушымта нигезендә;

Б) Теләче муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза үтәлә торган оешмалар исемлеге, 2 номерлы кушымта нигезендә.

2. Административ җаваплылыкка тартылган затлар мәҗбүри эшләрне үти торган оешмалар җитәкчеләренә Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында һәм хезмәт законнарында каралган бурычлар йөкләнә дип билгеләргә.

3. Тәкъдим итәргә:

А) әлеге Карарга 2 номерлы кушымтада күрсәтелгән оешмалар җитәкчеләренә мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү мәсьәләләре буенча суд приставлары хезмәтләре белән хезмәттәшлек өчен җаваплы хезмәткәрләрне билгеләргә;

Б) Саба һәм Теләче районнары буенча суд приставлары бүлегенә административ җәза билгеләнгән затларга административ җәза үтәү урыны итеп билгеләнгән оешмаларга хокукый һәм методик ярдәм күрсәтергә.

4. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 25 декабрендәге 1008 номерлы «Мәҗбүри эшләр төрләрен һәм мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәза үтәлә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«8» 04 2022 № 65
карарына 1 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районы территориясендә административ хокук бозган физик затлар тарафыннан башкарыла торган мәҗбүри эшләр төрләре

1. Торак пунктлар урамнарын җыештыру, яшелләндерү.

2. Паркларны, ял зоналарын җыештыру, яшелләндерү һәм төзекләндерү.

3. Юл техникасы өчен мөмкин булмаган урыннарны пычрактан һәм кар капламыннан чистарту.

4. Яр буен чистарту.

5. Торак пунктның җәмәгать урыннарын төзекләндерү.

6. Тротуарларны төзекләндерү буенча квалификацияләнмәгән эшләр.

7. Торак пунктларның җәмәгать урыннарында үсемлек культураларын кулдан агротехник карап тоту.

Эшләр идарәчесе И.Т. Һадиев

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«8» 04 2022 № 65
карарына 2 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза үтәлә торган оешмалар исемлеге

| № т/б | Оешманың исеме | Адресы | ИНН | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Әбде авыл җирлеге башкарма комитеты | 422084, Татарстан Республикасы, Теләче районы, Әбде ав., Школьная ур., 1 й. | 1619004394 | |
| 2. | Айдар авыл җирлеге башкарма комитеты | 422095, Татарстан Республикасы, Теләче районы, Айдар ав., Гагарин ур., 13а й. | 1619004436 | |
| 3. | Алан авыл җирлеге башкарма комитеты | 422085, Татарстан Республикасы, Теләче районы, Алан ав., Школьная ур., 1 й. | 1619004387 | |
| 4. | Баландыш авыл башкарма комитеты | 422098, Татарстан Республикасы, Теләче районы, Баландыш ав., Гагарин ур., 4 й. | 1619004362 | |
| 5. | Олы Мишә авыл җирлеге башкарма комитеты | 422088, Татарстан Республикасы, Теләче районы, Олы Мишә ав., Школьная ур., 1 й. | 1619004468 | |
| 6. | Олы Мәтәскә авыл җирлеге башкарма комитеты | 422082, Татарстан Республикасы, Теләче районы, Олы Мәтәскә авылы, Фатих Хөсни ур., 56а й. | 1619004411 | |
| 7. | Олы Нырсы авыл башкарма комитеты | 422094, Татарстан Республикасы, Теләче районы, Олы Нырсы ав., Школьная ур., 10 й. | 1619004450 | |
| 8. | Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты | 422083, Татарстан Республикасы, Теләче районы, Югары Кибәхуҗа ав., Ленин ур., 31 й., офис 1 | 1619004443 | |
| 9. | Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты | 422080, Татарстан Республикасы, Теләче районы, Кече Кибәхуҗа ав., Малая ур., 10 й. | 1619004429 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10. | Иске Җөри авыл җирлеге башкарма комитеты | 422091, Татарстан Республикасы, Теләче районы, Иске Җөри ав., Школьная ур., 1а й. | 1619004404 | |
| 11. | Үзәк авыл җирлеге башкарма комитеты | 422092, Татарстан Республикасы, Теләче районы, Үзәк п., Татарстан ур., 7 й. | 1619004370 | |
| 12. | Теләче авыл җирлеге башкарма комитеты | 422080, Татарстан Республикасы, Теләче районы, Теләче ав., Фатыйх Хөсни ур., 10 й. | 1619004203 | |
| 13. | Шәдке авыл җирлеге башкарма комитеты | 422096, Татарстан Республикасы, Теләче районы, Шәдке авылы, Габдулла Тукай ур., 7 й. | 1619004482 | |

Эшләр идарәчесе И.Т. Һадиев